| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2025 елның 13 ноябре № 3/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен раслау турында

«Максима» ЖЧЖ тарафыннан тәкъдим ителгән, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан алынган актуаль мәгълүматларны исәпкә алып төзәтелгән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре материалларын карап, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча 2025 елның 29 сентябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм 2025 елның 30 сентябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәсен, Чүпрәле муниципаль районы Советы депутатларының искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 7 һәм 29 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Яңа Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (www.droganoye.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге бүлегендә бастырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров